**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 елның 18 декабре №18

Бюджетара трансфертларны исәпләү
методикасын раслау турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль Законының 14 һәм 15 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.5 статьялары, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан, Татарстан Республикасы « Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына мөлкәт белән идарә итү, аннан файдалану, җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең милек объектлары реестрларының рәсми сайтларында бастырып чыгару буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру, шулай ук кушымта нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген расларга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**

Татарстан Республикасы
Яшел Үзән муниципаль районы
Олы Ачасыр авыл җирлеге
Советының 2020 елның
18 декабрендәге 18 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертларны исәпләү методикасы**

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең (алга таба-авыл җирлеге) мөлкәт белән идарә итү, алардан файдалану, алар белән эш итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының рәсми сайтында җирлек мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына җирлек вәкаләтләренең югарыда күрсәтелгән өлешен үтәүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен бирелә.

Җирлек вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру, мөлкәт (шул исәптән җир кишәрлекләре) белән эш итү, җирлекнең рәсми сайтларында җирлек мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча бюджетара трансфертлар катгый максатчан билгеләнешкә ия.

Трансфертлар катгый максатчан билгеләнешкә ия һәм әлеге методиканың 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тотыла.

Җирлек тарафыннан районга тапшырыла торган трансфертларның күләме
W= (R*K)/100 формула буенча билгеләнә, кайда

W - Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына трансфертларның еллык күләме
R – «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтнең гомуми күләменә карата, Яшел Үзән муниципаль районының 23 (егерме өч) муниципаль берәмлегенең гомуми милкенә карата процент чагылышында.

R= (U / V)*100, кайда
U - муниципаль берәмлек милкендә булган мөлкәт объектларының гомуми саны
V - Яшел Үзән муниципаль районының 23 (егерме өч) муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт объектларының гомуми саны
К - әйдәп баручы белгеч (муниципаль хезмәткәр) исәпләп чыгарган хезмәт хакы фонды)